# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында кабул ителде һәм җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, транспорт хезмәте күрсәтүләр базарында пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) арасындагы конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелде.

1 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

җиңел такси – гавами фрахтлау шартнамәсе нигезендә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен кулланыла торган "М1" категориясендәге транспорт чарасы;

пассажирлар йөртүче (багаж ташучы) – җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче юридик зат яисә индивидуаль эшкуар;

таксометр – узган ара берәмлегенә һәм (яисә) транспорт чарасыннан файдалануның вакыт берәмлегенә карата билгеләнгән тарифлардан чыгып, җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хакын исәпләп чыгару өчен билгеләнгән җайланма;

"М1" категориясендәге транспорт чарасы – пассажирлар йөртү өчен кулланыла торган һәм, транспорт чарасын йөртүче урыныннан тыш, утырту урыны сигездән артык булмаган транспорт чарасы.

2. Әлеге Законда кулланылучы бүтән төшенчәләр федераль законнардагы мәгънәсендә кулланыла.

2 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, "Юл хәрәкәте иминлеге турында" 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), бүтән федераль законнар һәм Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, шулай ук Татарстан Республикасының бүтән законнары һәм норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан рөхсәт алу**

1. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеге пассажирлар йөртүчеләрнең (багаж ташучыларның) җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан бирелә торган рөхсәтне (алга таба – рөхсәт) алу шарты белән гамәлгә ашырыла.

2. Рөхсәт җиңел такси сыйфатында кулланылучы һәр транспорт чарасына бирелә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтле орган билгели, шулай ук рөхсәтнең рәвешен, аның гамәлдә булу срогын, рөхсәт бирү һәм яңадан рәсмиләштерү тәртибен, рөхсәт, рөхсәт дубликатын биргән өчен түләү тәртибен һәм бирелгән рөхсәтләр реестрын алып бару тәртибен билгели.

4 статья. **Җиңел таксига, җиңел такси йөртүчегә, пассажирлар йөртүчегә (багаж ташучыга) карата таләпләр**

1. Җиңел такси, җиңел такси йөртүче, пассажирлар йөртүче (багаж ташучы) Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килергә тиеш.

2. Җиңел таксида түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) кузовы сары яисә ак төстә;

2) руль идарәсе сул якта урнашкан.

5 статья. **Билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж**

**ташучылар) тарафыннан үтәүне тикшереп тору тәртибе**

1. Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне тикшереп тору вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла (җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу процессында әлеге таләпләрне үтәүне турыдан-туры тикшереп торудан гайре).

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән тикшереп тору планлы һәм планнан тыш документар һәм күчмә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Түбәндәге көннән соң бер ел узу планлы тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планына кертү өчен нигез була:

1) юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга беренче рөхсәт бирелгән;

2) юридик затны яисә индивидуаль эшкуарны соңгы планлы тикшерү уздыру тәмамланган.

4. Планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләрне тикшерүдән, әлеге статьяның 7 һәм 9 өлешләрендә күрсәтелгән вәкаләтле органга шундый белешмәләре булган документлар кергәндә;

2) вәкаләтле органга Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләрне бозу фактлары турында гражданнарның, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, вәкаләтле органның вазыйфаи затыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керүдән, әгәр мондый хокук бозулар кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә зыян китерү куркынычы, техноген характердагы һәлакәтләр һәм (яисә) гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы тудырса йә мондый зыян килүгә һәм техноген характердагы һәлакәтләр һәм (яисә) гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерсә;

3) вәкаләтле орган җитәкчесенең планнан тыш тикшерү уздыру турында Федераль законның 9 статьясындагы 21 өлеше нигезендә чыгарылган боерыгы (күрсәтмәсе) булудан.

5. Планнан тыш күчмә тикшерү әлеге статьяның 4 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча прокуратура органы белән билгеләнгән тәртиптә килештергәннән соң вәкаләтле орган тарафыннан кичекмәстән уздырылырга мөмкин. Әлеге нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерү уздыру турында юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр итү таләп ителми.

6. Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 яисә 3 пунктларында каралган таләпләрне бозу ачыкланган очракта, вәкаләтле орган юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирә. Әлеге күрсәтмәдә аны үтәү срогы билгеләнә, ул бер айдан артмаска тиеш.

7. Күрсәтмә белән билгеләнгән срокта юридик зат яисә индивидуаль эшкуар вәкаләтле органга күрсәтмәне үтәү турында хисап җибәрә, аңа күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документлар кerә.

8. Бирелгән күрсәтмә үтәлмәгән очракта (шул исәптән әлеге күрсәтмәне үтәү

турындагы хисап шушы күрсәтмәдә билгеләнгән срок тәмамланганчы вәкаләтле органга тапшырылмаган яисә тапшырылган хисап әлеге күрсәтмәдә билгеләнгән срокта үтәүне расламаган очракта), вәкаләтле орган бер айдан да артмаган срокка рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул итә.

9. Рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы юридик зат яисә индивидуаль эшкуар рөхсәтнең үтәлмәве аның гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигез булган күрсәтмәне үтәүне раслый торган белешмәләре булган документларны вәкаләтле органга тапшырган очракта, вәкаләтле орган рөхсәтнең гамәлдә булуын яңарта. Рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору срогы тәмамланганчы юридик зат яисә индивидуаль эшкуар әлеге документларны вәкаләтле органга тапшырмаган йә тапшырылган документлар әлеге күрсәтмәне үтәүне расламаган очракта, вәкаләтле орган рөхсәтне чакыртып алу (юкка чыгару) турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итә. Рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору суд карары закон көченә кергәнче срокка озайтыла.

10. Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешендә һәм әлеге Законның 4 статьясында билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне тикшереп тору буенча әлеге статья белән җайга салынмаган тәртипкә карата, Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, "Дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

6 статья. **Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль ярдәм итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендәге эшчәнлекне үстерү буенча гамәлләр әзерләргә һәм тормышка ашырырга хокуклы, моңа җиңел таксиларның туктап тору урыннарын булдыру һәм тиешле программаларны раслау да керә.

2. Җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләр эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар, салым законнарына таянып, патент нигезендә салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана алалар.

7 статья. **Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык**

Әлеге Закон таләпләрен бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

8 статья. **Күчеш нигезләмәләре**

2013 елның 1 гыйнварына кадәр рөхсәт, рөхсәт дубликатын бирү һәм рөхсәтне яңадан рәсмиләштерү түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктыннан гайре, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 77-ТРЗ